КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 декабрь г.Казань № 1038

Тәтеш муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Челтәр компаниясе» ААҖнең Тәтеш муниципаль районында урнашкан, 0,004 гектары дәүләт милкендә, 0,0632 гектары Ф.Б.Галимов милкендә, 0,0064 гектары Г.Б.Шакирова милкендә булган 0,0736 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә энергетика объектларын (электр тапшыру линияләрен) урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:38:210202:87 | 0,0016 |
| 16:38:210202:88 | 0,0024 |
| 16:38:210202:90 | 0,0064 |
| 16:38:000000:847 | 0,0632 |
| Барысы | 0,0736. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин